СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

30 июнь 2026 ел г.Мензелинск № 3

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 20.06.2012 елдагы «Минзәлә муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» № 3 карарына үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 16 апрелендәге № 106-ФЗ «Реклама турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның 1 статьясы 3 өлеше нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый норматив актларга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге «Минзәлә муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары урнаштыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» №3 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 37 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) әгәр рөхсәтнамә 2006 елның 13 мартындагы № 38-ФЗ «Реклама турында» Федераль законның 19 статьясының 5 өлеше белән билгеләнгән таләпләрне бозу белән реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалану турында килешү төзегән затка бирелгән очракта; күпфатирлы йортта бүлмәләр ияләренең уртак милек объекты реклама конструкциясен урнаштыру һәм куллану өчен кулланылган очракта; яки аукцион яки конкурс нәтиҗәләре Россия Федерациясе хокукый норматив актларына туры китереп, гамәлдән чыгарылган дип табылган очракта;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының төзелеш, газлаштыру, электр белән тәэмин итү, элемтә, транспорт һәм юллар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе А. Ф. Сәлахов